КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь г.Казань № 1158

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 март, 248 нче карары белән расланган Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибен раслау хакында» 2019 ел, 30 март, 248 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август, 753 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укыту турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, максатчан

укыту турындагы шартнамә якларының аңа түләүдән азат итү тәртибе һәм нигезләре, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә аның күләмен һәм юнәлешен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең исемендә «раслау» сүзе алдына «әлеге чыгымнарны каплаудан азат итү тәртибен һәм нигезләрен» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3.10 – 3.11 пунктлар өстәргә:

«3.10. Мәгариф оешмасы югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укуга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән кабул ителгән гражданны укыту өчен тотылган чыгымнарны каплаудан түбәндәге очракларда азат ителә:

әгәр мәгариф оешмасы максатчан уку турындагы шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителгән булса;

әгәр мәгариф оешмасы максатчан уку турындагы шартнамәдә күрсәтелгән икътисадый эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыруны туктаткан булса;

әгәр мәгариф оешмасы бетерелгән булса;

яклар ихтыярына бәйле булмаган хәлләр булса (табигый бәла-казалар, аварияләр, эпидемияләр һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләр булганда).

3.11. Бу Тәртипнең 3.10 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең берсе булганда, югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укуга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән кабул ителгән гражданны укыту өчен тотылган чыгымнарны каплау турында бу Тәртипнең 3.6 пункты нигезендә хәбәрнамә алган мәгариф оешмасы чыгымнарны каплау турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокта, тиешле нигезнең булуын раслый торган документ (документлар) күчермәсен теркәп, тиешле нигезнең булуы турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына язма формада хәбәрнамә җибәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин